Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы

**КАРАР № IX**

Котлы Бөкәш ав. 15 нче февраль 2016 ел

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 26 декабрендәге XXXVII-1 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын тану турында

Авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен муниципаль районнарның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертү сәбәпле, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты, 3,4 өлешләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3,5 өлешләре, « Котлы Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының « Котлы Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 26 декабрендәге XXXVII-1 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмле Казаклар Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт, Сатлыган авылы, Ленин урамы, 25а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башлыгы Г.Г. Нәҗипов